ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

423732, Түке авылы,
Илтимер ур., 2 нче йорт.
Тел.3-44-61

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

423732, село Тюково,
ул. Илтимерова,дом 2,
Тел. 3-44-61

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№2 от 01.11.2019г.

Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлегенең Түке, Зөбәер,Чәчер торак пунктында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Түке авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Түке авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Чәчер авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 14 ноябренә билгеләргә.

1.1. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Зөбәер авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 14 ноябренә билгеләргә.

1.2. Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Түке авылы территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2019 нчы елның 21 ноябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

**Оештыру чикләрендә җирлектәге халыкны су белән тәэмин иту:**

-торак пунктларда суүткәргеч челтәрләрнең документациясен рәсмилэштеру,ремонтлау,карап тоту;

-чишмәләр территориясен тозекләндеру;

**Авыл җирлеге чикләрендә төзекләндеру эшләрен оештыру:**

-торак пунктлардагы социаль объектлар территориясен төзекләндеру;

**Авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**:

-торак пунктларында агымдагы ремонт,кардан чистарту, юлларны тигезләү ел дәвамында;

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Халык җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Чәчер авылы, Узәк урамы, 31йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Зөбәер авылы, Узәк урамы, 32йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы,Түке авылы, Илтимер урамы, 2йорт,

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Түке авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Түке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны уз остемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы Р.М.Нуртдинов